МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.08.2022 г.Казань № 797

Балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларын үзгәртеп кору яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү критерийларының әһәмиятен раслау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар өчен Татарстан Республикасының дәүләт милеге һәм (яисә) муниципаль милек булып торган социаль инфраструктура объектын үзгәртеп кору, модернизацияләү, аның билгеләнешен үзгәртү яисә аны бетерү турында, Татарстан Республикасының балалар өчен социаль инфраструктура булдыра торган дәүләт оешмасы, муниципаль оешмасы тарафыннан үзенә беркетелгән объектларның аренда шартнамәсен, алардан түләүсез нигездә файдалану шартнамәсен төзү турында, шулай ук Татарстан Республикасының балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы дәүләт оешмаларын, муниципаль оешмаларын үзгәртеп кору яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләренә бәяләү уздыру турында» 2022 елның 9 августындагы 775 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

Әлеге боерык кушымтасына туры китереп, балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларын үзгәртеп кору яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү критерийларының әһәмиятен расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау
министрлыгының 2022 елның
«23» 08. № 797 боерыгына
кушымта

## Балалар өчен социаль инфраструктура булдыручы Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларын үзгәртеп кору яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү критерийларының әһәмияте

| Критерийның атамасы | Критерийның әһәмияте |
|---|---|
| Балаларны социаль яклау һәм аларга үзгәртеп коруга яки бетерүгә тәкъдим ителә торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итү максатларында, балаларга социаль хезмәтләр күрсәтүне дәвам иттерү | Тәэмин ителгән / тәэмин ителмәгән |
| Тиешле карар кабул ителгәнчегә кадәр, балаларны социаль яклау һәм үзгәртеп коруга яки бетерүгә тәкъдим ителә торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган социаль хезмәтләр күләменнән ким булмаган күләмдә аларга социаль хезмәт күрсәтүләрне тәэмин итү максатларында, балаларга социаль хезмәтләр күрсәтү | Тәэмин ителгән / тәэмин ителмәгән |
| Үзгәртеп коруга яки бетерүгә тәкъдим ителә торган оешма тарафыннан гына гамәлгә ашырылган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыруны дәвам иттерүне тәэмин итү | Тәэмин ителгән / тәэмин ителмәгән |